КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 15 сентябрь г.Казань № 1143

2024 – 2026 елларга төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2024 – 2026 елларга дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен;

2024 – 2026 елларга төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан затларга, уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәре.

2. Бу карар белән расланган социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәре барлык милек рәвешләрендәге һәм ведомство буйсынуындагы мәгариф оешмаларында Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән төп гомуми,

урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары, эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү, квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программалары, урта звено белгечләре әзерләү программалары, бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары буенча белем алучы укучыларга кагыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2023 елга төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен раслау турында» 2022 ел, 1 сентябрь, 942 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәрен раслау турында» 2022 ел, 1 сентябрь, 942 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 ел, 28 апрель, 541 нче.

4. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 15 сентябрь, 1143 нче
карары белән расланды

2024 – 2026 елларга дәүләт һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмаларында төп мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләмнәре

| Т/с | Социаль ярдәм төрләре буенча түләүләр исеме | Ел | Түбәндәге программалар буенча белем алучыларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча түләүләр күләме, сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү | төп гомуми белем бирү базасында квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү | урта гомуми белем бирү базасында квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү | урта звено белгечләрен әзерләү | бакалавриат, специалитет, магистратура |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. | Төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яки) эшче һөнәрләр, хезмәткәр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары буенча көндезге формада белем алучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан затларга һәм белем алу чорында ата-анасының икесен дә яисә бердәнбер ата-анасын югалткан затларга белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны | 2024 | 935 | 935 | 935 | 935 | 935 |
| | | 2025 | 973 | 973 | 973 | 973 | 973 |
| | | 2026 | 1 012 | 1 012 | 1 012 | 1 012 | 1 012 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | тәмамлап чыкканда бер тапкыр бирелә торган акчалата пособие | | | | | | |
| 2. | Төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яки) эшче һөнәрләр, хезмәткәр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары буенча көндезге формада белем алучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан затларга һәм белем алу чорында ата-анасының икесен дә яисә бердәнбер ата-анасын югалткан затларга белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны тәмамлап чыкканда өс киемнәре, аяк киемнәре, йомшак инвентарь һәм җиһазлар сатып алуга бер тапкыр бирелә торган пособие | 2024 | 59 337 | 59 337 | 59 337 | 59 337 | 59 337 |
| | | 2025 | 59 337 | 59 337 | 59 337 | 59 337 | 59 337 |
| | | 2026 | 59 337 | 59 337 | 59 337 | 59 337 | 59 337 |
| 3. | Төп һөнәри белем бирү программалары буенча көндезге формада белем алучыларга ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга уку әдәбияты һәм язу өчен кирәк-яраклар сатып алуга ел саен бирелә торган пособие | 2024 | - | 3 339 | 3 339 | 3 339 | 8 636 |
| | | 2025 | - | 3 473 | 3 473 | 3 473 | 8 982 |
| | | 2026 | - | 3 612 | 3 612 | 3 612 | 9 342 |
| 4. | Төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яки) эшче һөнәрләр, хезмәткәр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары буенча көндезге формада белем алучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар | 2024 | 25 289 | 25 289 | 25 289 | 25 289 | 25 289 |
| | | 2025 | 25 289 | 25 289 | 25 289 | 25 289 | 25 289 |
| | | 2026 | 25 289 | 25 289 | 25 289 | 25 289 | 25 289 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | арасыннан затларга һәм белем алу чорында ата-анасының икесен дә яисә бердәнбер ата-анасын югалткан затларга кием комплекты, аяк киеме һәм йомшак инвентарь сатып алуга ел саен бирелә торган пособие | | | | | | |
| 5. | Төп һөнәри белем бирү программалары буенча белем алуның көндезге формасында белем алучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга һәм белем алу чорында ата-анасының икесен дә яисә бердәнбер ата-анасын югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга ай саен түләнә торган (тиешле елның 1 сентябренә кадәр түләнә торган) стипендия | 2024 | - | 1 110 | 1 110 | 1 110 | 1 110 |
| | | 2025 | - | 1 155 | 1 155 | 1 155 | 1 155 |
| | | 2026 | - | 1 202 | 1 202 | 1 202 | 1 202 |
| 6. | Төп һөнәри белем бирү программалары буенча белем алуның көндезге формасында белем алучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга һәм белем алу чорында ата-анасының икесен дә яисә бердәнбер ата-анасын югалткан затларга, инвалид балаларга, инвалидларга ай саен түләнә торган (тиешле елның 1 сентябреннән түләнә торган) стипендия | 2024 | - | 1 155 | 1 155 | 1 155 | 1 155 |
| | | 2025 | - | 1 202 | 1 202 | 1 202 | 1 202 |
| | | 2026 | - | 1 251 | 1 251 | 1 251 | 1 251 |
| 7. | Төп һөнәри белем бирү программалары һәм (яки) эшче һөнәрләр, хезмәткәр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары буенча көндезге формада белем алучы ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар һәм ата-ана | 2024 | 8 193 | 8 193 | 9 440 | 9 440 | 9 440 |
| | | 2025 | 8 521 | 8 521 | 9 818 | 9 818 | 9 818 |
| | | 2026 | 8 862 | 8 862 | 10 211 | 10 211 | 10 211 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан затларга һәм белем алу чорында ата-анасының икесен дә яисә бердәнбер ата-анасын югалткан затларга туклануга ай саен бирелә торган пособие | | | | | | |

___

Татарстан Республикасы
Министрлар
Кабинетының 2023 ел, 15
сентябрь, 1143 нче карары
белән расланды

2024 – 2026 елларга төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча белем алучы ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан затларга, уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга социаль ярдәм күрсәтү төрләре буенча
түләүләр күләмнәре

| Т/с | Социаль ярдәм төрләре буенча түләүләр исеме | Ел | Төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең мәгариф программалары буенча укучыларга социаль ярдәм төрләре буенча түләүләр күләме, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманы тәмамлаганда бер тапкыр бирелә торган акчалата пособие | 2024 | 935 |
| | | 2025 | 973 |
| | | 2026 | 1 012 |
| 2. | Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга өс киемнәре, аяк киемнәре, йомшак инвентарь һәм җиһазлар сатып алу өчен мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманы тәмамлаганда бер тапкыр бирелә торган пособие | 2024 | 59 337 |
| | | 2025 | 59 337 |
| | | 2026 | 59 337 |
| 3. | Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга уку әдәбияты һәм язу өчен кирәк-яраклар сатып алуга ел саен бирелә торган пособие | 2024 | 3 339 |
| | | 2025 | 3 473 |
| | | 2026 | 3 612 |
| 4. | Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен | 2024 | 25 289 |
| | | 2025 | 25 289 |
| | | 2026 | 25 289 |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | генә югалткан затларга өс киемнәре, аяк киемнәре һәм йомшак инвентарь сатып алу өчен ел саен бирелә торган пособие | | |
| 5. | Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында атасын да, анасын да яки берсен генә югалткан затларга туклану өчен ай саен бирелә торган пособие | 2024 | 8 193 |
| | | 2025 | 8 521 |
| | | 2026 | 8 862 |

---